# Красногорскида «Төзелеш навигаторы: цифрлаштыру курсы. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге» Бөтенроссия тармак конференциясе узды

«Төзелеш навигаторы: цифрлаштыру курсы. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге» – Красногорскида шундый исем астында Бөтенроссия тармак конференциясе узды.

Россия Төзелеш министрлыгы ярдәме белән аның инициаторлары булып Мәскәү өлкәсенең Дәүләт төзелеш күзәтчелеге баш идарәсе һәм «Мәгълүмати модельләштерү технологияләре өлкәсендә оешмаларның илкүләм берләшмәсе» ассоциациясе (НОТИМ) чыгыш ясады.

Мәскәү өлкәсенең төзелеш күзәтчелеген цифрлаштыру өлкәсендәге тәҗрибәсен өйрәнергә бөтен илдән төбәк күзәтчелек органнары, капиталь төзелеш заказчылары, төзүчеләр, проектлаучылар вәкилләре килгән иде. Алар арасында цифрлы аралашу нокталарын эзләү өчен диалог узды.

«Төзелеш навигаторы: цифрлаштыру курсы. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге» Бөтенроссия тармак конференциясе эшендә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы Вәли Нәҗмиев катнашты.

*Төп фотода: өлкә һәм төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекцияләре җитәкчеләре – 5 июльдә Мәскәү өлкәсенең Красногорск шәһәрендә уздырылган «Төзелеш навигаторы: цифрлаштыру курсы. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге» Бөтенроссия тармак конференциясендә катнашучылар. Чарада катнашучылар арасында – Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы Вәли Нәҗмиев.*


ВСЕРОССИЙСКАЯ ОТРАСЛЕВАЯ КОНФЕРЕНЦИЯ
СТРОИТЕЛЬНЫЙ НАВИГАТОР 2024
Курс на цифровизацию. Госстройнадзор
Организаторы:
При поддержке:
МИНСТРОЙ РОССИИ
ГЛАВГОСЭКСПЕРТИЗА РОССИИ
ПРАВИТЕЛЬСТВО МОСКОВСКОЙ ОБЛАСТИ

